**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2016 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1, № 9 (II часть); 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть) следующие изменения:

1) в абзаце восьмом части 5 статьи 10 слова «должностях правоохранительной службы» заменить словами «должностях федеральной государственной службы иных видов»;

2) в части 5 статьи $11^3$ слова «классных чинов правоохранительной службы» заменить словами «классных чинов юстиции, классных чинов прокурорских работников»;

3) в статье 19:
а) в абзаце втором части 6 слово «рабочий» заменить словом «служебный»;
б) часть 7 признать утратившей силу;
в) дополнить частями $8^1$ – $8^3$ следующего содержания:
«$8^1$. Минимальная продолжительность ежегодного оплачиваемого отпуска, используемого государственным служащим в служебном году, за который предоставляется ежегодный оплачиваемый отпуск, не может быть менее 28 календарных

дней. При этом хотя бы одна из частей ежегодного оплачиваемого отпуска должна составлять не менее 14 календарных дней.

8[2]. В исключительных случаях, если предоставление государственному служащему ежегодного оплачиваемого отпуска общей продолжительностью, исчисленной в соответствии с частью 6 настоящей статьи, в текущем служебном году может неблагоприятно отразиться на осуществлении задач и функций государственного органа или на осуществлении полномочий лица, замещающего государственную должность, по решению представителя нанимателя и с письменного согласия государственного служащего допускается перенесение части ежегодного оплачиваемого отпуска, превышающей 28 календарных дней, на следующий служебный год. При этом перенесенная часть ежегодного оплачиваемого отпуска должна быть использована не позднее 12 месяцев после окончания того служебного года, за который эта часть отпуска предоставляется.

8[3]. Часть ежегодного оплачиваемого отпуска, превышающая 28 календарных дней, или любое количество дней из этой части по письменному заявлению государственного служащего могут быть заменены денежной компенсацией.».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 7 июня 2004 года № 37-ЗРТ «О Счетной палате Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 65-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 6; 2011, № 10 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 6 (I часть) следующие изменения:

1) часть 4 статьи 8 изложить в следующей редакции:

«4. Председатель Счетной палаты, заместитель Председателя Счетной палаты и аудиторы Счетной палаты обязаны представлять сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей по каждой сделке по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг, акций (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций), совершенной им, его супругой (супругом) и (или) несовершеннолетними детьми в течение календарного года, предшествующего году представления сведений (далее – отчетный период), если общая сумма таких сделок превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду, и об источниках получения средств, за счет которых совершены эти сделки, в порядке, установленном федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, принимаемыми в соответствии с ними нормативными правовыми актами Республики Татарстан.»;

2) часть 2 статьи 9 после слов «распространяются ограничения» дополнить словами «и обязанности»;

3) часть 1 статьи 10 изложить в следующей редакции:

«1. Председатель Счетной палаты, заместитель Председателя Счетной палаты, аудиторы Счетной палаты освобождаются от должности на основании решения Государственного Совета Республики Татарстан в случае:

1) истечения срока полномочий;

2) смерти;

3) в случаях, предусмотренных частью 5 статьи 8 Федерального закона от 7 февраля 2011 года № 6-ФЗ «Об общих принципах организации и деятельности контрольно-счетных органов субъектов Российской Федерации»;

4) в случаях, предусмотренных Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» и иными федеральными законами.».

**Статья 3**

Внести в Закон Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 3 (I часть); 2007, № 7 (I часть); 2008, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (II часть); 2010, № 1 – 2, № 4 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть) следующие изменения:

1) в статье 8:

а) в пункте 8 части 1 слово «, акции» и слово «, акциями» исключить;

б) в части 2 слова «замещаемую на постоянной основе,» исключить;

в) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Лица, замещающие государственные должности Республики Татарстан, обязаны сообщать в порядке, установленном федеральными законами и принимаемыми в соответствии с ними нормативными правовыми актами Республики Татарстан, о возникновении личной заинтересованности при исполнении должностных обязанностей, которая приводит или может привести к конфликту интересов, а также принимать меры по предотвращению или урегулированию такого конфликта.»;

2) статью 9 после слов «ограничения» дополнить словом «, обязанности»;

3) дополнить статьей $9^1$ следующего содержания:

« Статья $9^1$. **Порядок принятия лицами, замещающими отдельные государственные должности Республики Татарстан, почетных и специальных званий, наград и иных знаков отличия иностранных государств, международных организаций, политических партий, иных общественных объединений и других организаций**

1. Порядок принятия Премьер-министром Республики Татарстан, а также лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, назначение на которые и освобождение от которых осуществляется Президентом Республики Татарстан, почетных и специальных званий, наград и иных знаков отличия (за исключением научных и спортивных) иностранных государств, международных ор-

ганизаций, политических партий, иных общественных объединений и других организаций устанавливается указом Президента Республики Татарстан.

2. Порядок принятия лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, избрание или назначение на которые осуществляются Государственным Советом Республики Татарстан (за исключением судей Конституционного суда Республики Татарстан и мировых судей Республики Татарстан), почетных и специальных званий, наград и иных знаков отличия (за исключением научных и спортивных) иностранных государств, международных организаций, политических партий, иных общественных объединений и других организаций устанавливается постановлением Государственного Совета Республики Татарстан.»;

4) в части 2 статьи 10 слова «замещаемые на постоянной основе,» исключить.

**Статья 4**

Внести в статью 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 5, № 12 (I часть); 2010, № 6; 2011, № 8 (I часть), № 12 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5) изменение, дополнив ее частью $13^3$ следующего содержания:

«$13^3$. Член Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан с правом решающего голоса, член иной избирательной комиссии, действующей на постоянной основе и являющейся юридическим лицом, с правом решающего голоса, работающие в указанных комиссиях на постоянной (штатной) основе, обязаны сообщать о возникновении личной заинтересованности при исполнении должностных обязанностей, которая приводит или может привести к конфликту интересов, а также принимать меры по предотвращению или урегулированию такого конфликта в порядке, установленном законом.».

**Статья 5**

Внести в Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть) следующие изменения:

1) в статье 8:

а) в части 1 слова «(государственной службы)» исключить;

б) в части 5 слова «и правоохранительной службы» заменить словами «службы и должностях федеральной государственной службы иных видов»;

2) в пункте 11 части 1 статьи 14 слова «своего непосредственного начальника» заменить словами «представителя нанимателя (работодателя)»;

3) в пункте 5 части 1 статьи 16 слова «Российской Федерации;» заменить словами «Российской Федерации. Муниципальный служащий, сдавший подарок, полученный им в связи с протокольным мероприятием, со служебной командировкой

или с другим официальным мероприятием, может его выкупить в порядке, устанавливаемом нормативными правовыми актами Российской Федерации;»;

4) в статье 17:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Для целей настоящего Кодекса используется понятие «конфликт интересов», установленное частью 1 статьи 10 Федерального закона «О противодействии коррупции».»;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Для целей настоящего Кодекса используется понятие «личная заинтересованность», установленное частью 2 статьи 10 Федерального закона «О противодействии коррупции».»;

в) в части 4 слово «, акциями» и слово «, акции» исключить;

5) в части 3 статьи 27 слова «Законами Республики Татарстан и уставом» заменить словом «Уставом»;

6) в статье 28:

а) в части 2 слова «пунктами 2 (в случае истечения срока трудового договора в связи с истечением установленного срока полномочий лица, замещавшего муниципальную должность, для непосредственного обеспечения исполнения полномочий которого учреждена должность, замещавшаяся муниципальным служащим), 5 (в случае перевода на государственную службу или перехода на выборную работу (должность), 8 и 9 части первой статьи 77, пунктами 1, 2 части первой статьи 81, пунктами 2, 5 и 7 части первой статьи 83 Трудового кодекса Российской Федерации» заменить словами «пунктом 1 части 1 статьи 19 Федерального закона «О муниципальной службе в Российской Федерации», пунктами 1, 2 (за исключением случаев истечения срока трудового договора в связи с истечением установленного срока полномочий лица, замещавшего муниципальную должность, для непосредственного обеспечения исполнения полномочий которого учреждена должность, замещавшаяся муниципальным служащим), 3 и 7 части первой статьи 77, пункта 3 части первой статьи 81 Трудового кодекса Российской Федерации»;

б) в части 4 четвертое предложение исключить;

в) дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. В случае, если размер пенсии за выслугу лет, определенный в соответствии с частью 4 настоящей статьи, не превышает фиксированной выплаты к страховой пенсии по старости, установленной в соответствии с частью 1 статьи 16 Федерального закона «О страховых пенсиях», пенсия за выслугу лет выплачивается в размере, равном указанной фиксированной выплате к страховой пенсии по старости.»;

г) в части 5 слова «государственной пенсии за выслугу лет» заменить словами «пенсии за выслугу лет»;

д) часть 9 после слов «по заявлению гражданина,» дополнить словами «поданному в том числе в форме электронного документа,»;

е) часть 14 после слов «со дня подачи заявления,» дополнить словами «в том числе в форме электронного документа,»;

ж) часть 15 после слов «по их заявлению» дополнить словами «, поданному в том числе в форме электронного документа,»;

з) абзац второй части 16 после слов «по заявлению пенсионера» дополнить словами «, поданному в том числе в форме электронного документа,»;

7) в статье 29:

а) в части 1:

в абзаце первом после слова «службы» дополнить словами «для назначения пенсии за выслугу лет»;

дополнить пунктом 12 следующего содержания:

«12) иных должностях в соответствии с федеральными законами.»;

б) часть 2 после слов «муниципальной службы» дополнить словами «для назначения пенсии за выслугу лет»;

в) в части 3 слова «В стаж муниципальной службы» заменить словами «В стаж муниципальной службы для назначения пенсии за выслугу лет»;

г) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. В стаж муниципальной службы для определения продолжительности ежегодного дополнительного оплачиваемого отпуска за выслугу лет, предоставляемого муниципальным служащим, и установления им других гарантий, предусмотренных федеральными законами, настоящим Кодексом и уставами муниципальных образований, включаются (засчитываются) периоды замещения должностей, указанных в части 1 статьи 25 Федерального закона «О муниципальной службе в Российской Федерации», а также периоды замещения должностей, включаемые (засчитываемые) в стаж государственной гражданской службы в соответствии с частью 2 статьи 54 Федерального закона от 27 июля 2004 года № 79-ФЗ «О государственной гражданской службе Российской Федерации».».

**Статья 6**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

2. Сохранить для государственных гражданских служащих Республики Татарстан, имеющих на день вступления в силу настоящего Закона неиспользованные ежегодные оплачиваемые отпуска или части этих отпусков, право на их использование, а также право на выплату денежной компенсации за неиспользованные ежегодные оплачиваемые отпуска или части этих отпусков.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ / ГОМУМИ БҮЛЕК — АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
21 апреля 2016 года
№ 22-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 5 өлешендәге сигезенче абзацында “хокук саклау хезмәте вазыйфаларында” сүзләрен “федераль дәүләт хезмәтенең башка төрләре вазыйфаларында” сүзләренә алмаштырырга;

2) $11^3$ статьяның 5 өлешендә “хокук саклау хезмәтенең класслы чиннарының” сүзләрен “юстициянең класслы чиннарының, прокурор хезмәткәрләренең класслы чиннарының” сүзләренә алмаштырырга;

3) 19 статьяда:
а) 6 өлешнең икенче абзацында “эш” сүзен “хезмәт” сүзенә алмаштырырга;
б) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
в) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ – $8^3$ өлешләр өстәргә:
“$8^1$. Еллык түләүле отпуск бирелә торган хезмәт елында дәүләт хезмәткәре файдалана торган еллык түләүле отпускның минималь дәвамлылыгы 28 календарь көннән ким була алмый. Еллык түләүле отпускның бер өлеше 14 календарь көннән ким булмаска тиеш.

8². Аерым очракларда, әгәр дәүләт хезмәткәренә гомуми дәвамлылыгы әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә исәпләнгән еллык түләүле отпускны бирү агымдагы хезмәт елында дәүләт органының бурычларын һәм функцияләрен башкаруга яисә дәүләт вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга тискәре йогынты ясый алса, яллаучы вәкиленең карары һәм дәүләт хезмәткәренең язма ризалыгы белән еллык түләүле отпускның 28 календарь көннән артык булган өлешен киләсе хезмәт елына күчерү рөхсәт ителә. Еллык түләүле отпускның күчерелгән өлеше отпускның шушы өлеше бирелә торган шул хезмәт елы тәмамланганнан соң 12 айдан да соңга калмыйча файдаланылырга тиеш.

8³. Еллык түләүле отпускның 28 календарь көннән артык булган өлеше яисә шушы өлешнең теләсә күпме көне дәүләт хезмәткәренең язма гаризасы буенча акчалата компенсация белән алмаштырылырга мөмкин.".

**2 статья**

"Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы үзе, хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган балалары белешмәләр тапшыру елыннан алдагы календарь ел (алга таба – хисап чоры) дәвамында кылган һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә белешмәләр тапшырырга тиеш.";

2) 9 статьяның 2 өлешендә "чикләүләр" сүзеннән соң "һәм бурычлар" сүзләрен өстәргә;

3) 10 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә вазыйфаларыннан азат ителәләр:

1) вәкаләтләр срогы тәмамланганда;

2) вафат булганда;

3) “Россия Федерациясе субъектларының контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында” 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракларда;

4) “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган очракларда.”.

**3 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында” 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 1 өлешнең 8 пунктында “, акцияләргә” сүзен һәм “, акцияләрне” сүзен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә “даими нигездә биләнүче” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында федераль законнарда һәм Татарстан Республикасының алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә хәл итү чараларын күрергә тиеш.”;

2) 9 статьяда “чикләүләр” сүзеннән соң “, бурычлар” сүзен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ статья өстәргә:

“$9^1$ статья. **Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит илләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка мактау билгеләрен алу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры, шулай ук вазыйфаларына билгеләп куелуы һәм алардан азат ителүе Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит илләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның

мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка мактау билгеләрен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш) алу тәртибе Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

2. Вазыйфаларына сайлануы яисә билгеләп куелуы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар (Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларыннан һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларыннан тыш) тарафыннан чит илләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка мактау билгеләрен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш) алу тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән билгеләнә.";

4) 10 статьяның 2 өлешендә "даими нигездә биләнүче" сүзләрен төшереп калдырырга.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6; 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5), аңа түбәндәге эчтәлекле $13^3$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

"$13^3$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия даими (штат) нигезендә эшләүче әгъзасы һәм даими нигездә эшләүче, юридик зат булып торучы башка сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия даими (штат) нигезендә эшләүче әгъзасы вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында законда билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә хәл итү чараларын күрергә тиеш.".

**5 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 1 өлештә "(дәүләт хезмәте)" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 5 өлештә "хәрби һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларындагы" сүзләрен "хәрби хезмәтнең һәм федераль дәүләт хезмәтенең башка төрләре вазыйфаларындагы" сүзләренә алмаштырырга;

2) 14 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктында “турыдан-туры башлыгына” сүзләрен “яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә)” сүзләренә алмаштырырга;

3) 16 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында “тапшырыла;” сүзен “тапшырыла. Протокол чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;” сүзләренә алмаштырырга;

4) 17 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Әлеге Кодекс максатларында “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның 10 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән “мәнфәгатьләр конфликты” төшенчәсе кулланыла.”;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Әлеге Кодекс максатларында “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән “шәхси кызыксыну” төшенчәсе кулланыла.”;

в) 4 өлештә “, акцияләргә” сүзен һәм “, акцияләрне” сүзен төшереп калдырырга;

5) 27 статьяның 3 өлешендә “Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль берәмлек уставы” сүзләрен “Муниципаль берәмлек уставы” сүзләренә алмаштырырга;

6) 28 статьяда:

а) 2 өлештә “Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 2 (муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа муниципаль вазыйфаны биләгән зат вәкаләтләренең үтәлешен турыдан-туры тәэмин итү өчен булдырылып, муниципаль вазыйфаны биләгән затның билгеләнгән вәкаләтләр срогы тәмамлануга бәйле рәвештә хезмәт шартнамәсе срогы беткән очракта), 5 (дәүләт хезмәтенә күчерелгән яисә сайланулы эшкә (вазыйфага) күчкән очракта), 8 һәм 9 пунктларында, 81 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2 пунктларында, 83 статьясындагы беренче өлешенең 2, 5 һәм 7 пунктларында” сүзләрен “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2 (муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа муниципаль вазыйфаны биләгән зат вәкаләтләренең үтәлешен турыдан-туры тәэмин итү өчен булдырылып, муниципаль вазыйфаны биләгән затның билгеләнгән вәкаләтләр срогы тәмамлануга бәйле рәвештә хезмәт шартнамәсе срогы беткән очраклардан тыш), 3 һәм 7 пунктларында, 81 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктында” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

“4[1]. Әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән тиешле еллар эшләгән өчен пенсиянең күләме картлык буенча иминият пенсиясенә «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлеше нигезендә билгеләнеп беркетелгән түләүдән кимрәк булса, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия картлык буенча иминият пенсиясенә шушы беркетелгән түләүгә тигез күләмдә түләнә.”;

г) 5 өлештә “тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенең” сүзләрен “тиешле еллар эшләгән өчен пенсиясенең” сүзләренә алмаштырырга;

д) 9 өлештә “гражданның гаризасы” сүзләреннән соң “, шул исәптән электрон документ рәвешендә бирелгәне” сүзләрен өстәргә;

е) 14 өлештә “гариза биргән” сүзләреннән соң “, шул исәптән электрон документ рәвешендә биргән” сүзләрен өстәргә;

ж) 15 өлештә “аларның гаризалары” сүзләреннән соң “, шул исәптән электрон документ рәвешендә бирелгәннәре” сүзләрен өстәргә;

з) 16 өлешнең икенче абзацында “пенсионер гаризасы” сүзләреннән соң “, шул исәптән электрон документ рәвешендә бирелгәне” сүзләрен өстәргә;

7) 29 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта “Муниципаль хезмәт” сүзләре алдыннан “Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен” сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

“12) федераль законнар нигезендә башка вазыйфаларда.”;

б) 2 өлештә “биләү чорлары” сүзләреннән соң “тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен” сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә “Муниципаль хезмәт стажына” сүзләрен “Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына” сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгын билгеләү һәм аларга федераль законнарда, әлеге Кодекста һәм муниципаль берәмлекләр уставларында каралган башка гарантияләрне билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 25 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән вазыйфаларны биләү чорлары, шулай ук “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 2 өлеше нигезендә дәүләт граждан хезмәте стажына керә торган (исәпләнә торган) вазыйфалар биләү чорлары керә (исәпләнә).”.

**6 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә файдаланылмаган еллык түләүле отпусклары яисә шушы отпускларның өлешләре булган Татарстан Республикасы

дәүләт граждан хезмәткәрләренең алардан файдалану хокукын, шулай ук файдаланылмаган еллык түләүле отпусклар яисә шушы отпускларның өлешләре өчен акчалата компенсация алу хокукын саклап калырга.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 21 апреле
№ 22-ТРЗ